БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«28» 01 2019г.** **№ 52**

**Муниципаль белем бирү оешмаларын Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының конкрет территорияләренә беркетү турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының "Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү өчен гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында" 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы нигезендә һәм Балтач муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын комплектлаштыруны тәртипкә салу максатларында, Балтач районы башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Муниципаль белем бирү оешмаларын Балтач муниципаль районы территорияләренә 1 нче кушымта нигезендә беркетергә.
2. Балтач муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә Балтач муниципаль районы территориясендә гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан беркетелгән төп гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында белем алырга тиешле балаларның исәбен алып баруны тәэмин итәргә.
3. Балтач муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының аерым территорияләренә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын беркетү турында” 2018 елның 1 февралендәге 65 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының , “Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә гомуми белем бирү оешмаларының рәсми сайтларында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (иҗтимагый сораулар буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов